КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

29.03.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 елның 26, 27, 28, 29 нчы мартында узган гражданнар җыенының йомгаклау протоколы тәзелде «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 24.11.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә « 2024 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау (туфрак эшкәртү, ком нигезен төзү, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән торак пунктында җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән җәяүлеләр тротуарларын оештыру;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән торак пунктында ял итү мәйданчыгын төзекләндерү дигән сораулар буенча 2023 елның 24 нче ноябендә узган халык җыены 1 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртергә:
- Шәмәрдән торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау (туфрак эшкәртү, ком нигезен төзү, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Шәмәрдән торак пунктында җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән җәяүлеләр тротуарларын оештыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктында ял итү мәйданчыгын төзү, төзекләндерү) ризамы» дигән сорау буенча 2024 елның 29 мартында узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 4542 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 2317 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 2317 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 24.11.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә, 24.11.2023 елгы 1 нче карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртүгә:

- Шәмәрдән торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау (туфрак эшкәртү, ком нигезен төзү, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);

- Шәмәрдән торак пунктында җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән җәяүлеләр тротуарларын оештыру;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктында ял итү мәйданчыгын төзү, төзекләндерү) ризамы» карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shtmordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында<br>рәислек итүче,<br>Шәмәрдән авыл<br>җирлеге башлыгы А.К.Вәлиев